ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«19» август 2021 ел** **№ 591**

**Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында**

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» Арча район башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 1218 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре (алга таба - компенсация түләүләре) бирү тәртибенкушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ җитәкчесенә йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
19 август 2021 ел, №591
карары белән расланды

**Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибе**

**1.Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Тәртип мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен (алга таба - компенсация) билгеләү һәм түләү тәртибен, шартларын билгели.

1.2. Компенсация белем бирү оешмасы белән килешү төзегән һәм тиешле белем бирү оешмасына караган өчен ата-ана түләве керткән вәкаләтле затка (ата-ана, уллыкка алучы, опекун) яисә аның вәкаләтле вәкиленә (алга таба - мөрәҗәгать итүче) гаиләнең җан башына уртача керемен исәпкә алып билгеләнә һәм түләнә.

1.3.Компенсация түләү өчен гаиләнең җан башына туры килә торган кереме компенсация билгеләү турында гариза кергән айдан алда килгән алты календарь ай өчен билгеләнә (алга таба - хисап чоры).

1.4. Компенсация алуга хокукны билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме "Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында" 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган "Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында" 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.

2021 елның 1 апреленнән мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карап торган өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүнең бер өлешенә өстәмә компенсация билгеләү гаиләнең җан башына уртача кереме 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә аны билгеләү турында гариза биргән ай алдыннан

килгән алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь айда гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.

1.5. Компенсация күләмен билгеләгәндә гаилә составында түбәндәгеләр исәпкә алына:

Асрамада (иждивение) булган һәм 18 яшькә җитмәгән балалар, шул исәптән хастаханәләрдә, балалар шифаханәләрендә дәвалануда булган балалар, шулай ук интернат-мәктәпләрдә матди караган өчен ата-аналары өлешчә түләү кертә торган балалар;

көндезге формада белем алучы 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге (никахта тормаган) балалар, шул исәптән, ата-аналары белән уртак яшәү фактына бәйсез рәвештә, дәүләтнеке булмаган уку учреждениеләрендә;

башка ата-ана гаиләсендә исәпкә алынмаган очракта, үги малайлар һәм үги кызлар;

гражданнар гаиләләрендә опекада торучы балалар;

тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар.

1.6. Гаилә составында түбәндәге балалар исәпкә алынмый:

аларга карата ата-ана (бер ата яки ана - тулы булмаган гаиләдә) ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгәндә;

тулы дәүләт тәэминатында торганнар.

1.7. Компенсация күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

ДК= Ф x (100-МДД) - К, биредә

ДК - компенсация күләме;

Ф- башкарма комитет карары белән расланган ата-ана түләве күләме чикләрендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасына баланы карап торган өчен фактта алына торган ата-ана түләве күләме;

МДД - таблица нигезендә билгеләнә торган, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы карап торган өчен ата-ана түләвенә гражданнарның чыгымнарының максималь мөмкин булган өлеше;

К - "Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында" Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы карары белән мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы карап торган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү күләме.

Таблица

**Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы карап торган өчен ата-ана түләвенә гражданнарның максималь рөхсәт ителгән чыгымнары**

| Гаиләнең бер әгъзасына керем күләме | Ата-ана түләвенә гражданнар чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше (%) | | |
|---|---|---|---|
| | 1 балага | 2 балага | 3 балага |
| 10 000 сумга кадәр | 60 | 38 | 23 |
| 10 001 дән 15 000 сумга кадәр | 70 | 43 | 36 |
| 15 001 дән 20 000 сумга кадәр | 80 | 53 | 53 |
| 20 000 сумнан артык | 100 | 100 | 100 |
| Яшәү минимумыннан түбәнрәк (күпбалалы гаилә өчен) | 0 | 0 | 0 |

## 2. Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе

2.1. Компенсация алу өчен мөрәҗәгать итүче яшәү урыны буенча Арча муниципаль районында (әгәр мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлүе булмаса) компенсация түләүгә вәкаләтле органга (алга таба - вәкаләтле орган) түбәндәге документларны тапшыра:

а) компенсация билгеләү турында гариза;

b) өстәмә компенсация бирү турында гариза бирелгән айга кадәрге унике ай эчендә гаиләнең һәр әгъзасы керемнәре турында документлар;

c) мөрәҗәгать итүче башка балаларның анасы, атасы (законлы вәкиле ) булганда, башка балаларның туу (уллыкка алыну) турында таныклык күчермәсе (күчермәсе нотариаль таныкланмаган булса, төп нөсхәсен күрсәтеп). Опекада булган балага компенсация билгеләү өчен өстәмә рәвештә балага опека билгеләү турында җирле үзидарә органнары карарыннан өземтә тапшырыла;

d) ышанычлы затлар өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә күчермәсе;

e) ата яки ана (ата-ана) балага (балаларга) карата ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән очракта, суд карары;

f) гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан яисә аларның законлы вәкилләреннән документ (ирекле формада):

g) аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булу;

h) персональ мәгълүматларны органга яисә оешмага тапшырганда, мөрәҗәгать итүченең үз исеменнән эш итәргә вәкаләте.

с пунктчасындагы белешмәләрне компенсацияләр түләүгә вәкаләтле орган ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып ала.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә паспортын (аны алмаштыручы документ), компенсацияне банк аша алганда мәгариф оешмасы белән килешү төзегән затның кредит оешмасында шәхси счет номерын күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнгә гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) уртача җан башына керемен исәпкә алып билгеләнгән социаль ярдәм чараларын алучы булса, мөрәҗәгать итүче керемнәр турында белешмәләр тапшыру бурычыннан азат ителә.

Мөрәҗәгать иткән көнгә мөрәҗәгать итүче "Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18

гыйнварындагы 9 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы карап торган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алучы булса, 2.1 пунктындагы белешмәләрне тапшыру бурычыннан азат ителә.

2.2. Гариза һәм документлар почта аша җибәрелергә мөмкин. Гаризаны һәм документларны почта аша җибәрү вәкаләтле орган алу фактын һәм датасын расларга мөмкинлек бирә торган ысул белән гамәлгә ашырыла.

2.3. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә вәкаләтле орган барлык кирәкле документлар белән гаризаны теркәгән көннән алып 10 көн эчендә компенсация билгеләү турында яисә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән хәбәр итә (хат, смс-хәбәр, электрон почта, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша мөрәҗәгать итүчеләр өчен - шәхси кабинетта хәбәрнамә).

2.4. Компенсация билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр:

әлеге Тәртипнең 2.1пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;

гамәлдә булу вакыты үткән документлар тапшыру (күрсәтү);

законнар таләпләрен бозып тутырылган документлар тапшыру.

2.5. Компенсация барлык кирәкле документлар белән гариза биргән айдан билгеләнә һәм 6 ай дәвамында түләнә.

2.6. Гражданнар торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә элек билгеләнгән субсидия яисә балага айлык пособие алган очракта, граждан гаризасы буенча компенсация субсидия бирү срогы яисә балага айлык пособие бирү срогы тәмамланганчыга кадәр билгеләнергә мөмкин.

Әгәр компенсация алучы торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия билгеләү яисә балага айлык пособие билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән граждан гаиләсе составына керсә, элегрәк билгеләнгән компенсация, алучының гаризасы буенча, субсидия алучы тарафыннан бирелгән субсидияләрне яки айлык балалар пособиесен исәпкә алып, балага субсидия яки айлык пособие алу чорына кабат билгеләнергә мөмкин..

2.7. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга өстәмә компенсация алу хокукын яңа срокка рәсмиләштерү алдагы 3 ай дәвамында (июль, август, сентябрь) мөрәҗәгать итү аена кадәр өстәмә компенсация түләмичә график буенча башкарыла.

2.8. Махсус оешмаларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан мәгълүмати хезмәттәшлек, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырылган ведомствоара мәгълүмати бәйләнешнең региональ системаларын кулланып эш бирүче (иминләштерүче) физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм бүтән түләүләр суммасы турында мәгълүмат кертелгәннән соң, компенсация билгеләү аның гаризада күрсәтелгән ризалыгы белән Россия Федерациясе Пенсия фондында булган мәгълүматлар нигезендә, мөрәҗәгать итүчедән компенсация билгеләү турында мөрәҗәгать кергән айдан алда килгән 12 айның соңгы 6 ае өчен башкарыла.

**3. Йомгаклау нигезләмәләре**

3.1. Мөрәҗәгать итүче тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алар булган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

3.2. Документларның дөреслеге һәм тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге буенча шик туган очракларда, вәкаләтле орган мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган белешмәләрне өстәмә тикшерергә хокуклы.

3.3. Компенсация суммасы мөрәҗәгать итүченең банк счетына күчерелә.

Сәламәтлеге торышы, яше, җәяү йөри алмавы яисә транспорт белән тәэмин ителмәве аркасында банкта счет ачу һәм аннан файдалану мөмкинлеге булмаганда, гариза бирүчегә компенсация түләүләре гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзелгән оешманың акчалата түләүләр китерүче башка оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

3.4. Түләүне банктагы счетка күчерү, почта аша яисә гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзелгән оешма тарафыннан китерүне гамәлгә ашыру компенсацияләрне исәпләү ае дәвамында башкарыла.

3.5. Гражданнар компенсация түләү тукталуга китерә торган хәлләр (белем бирү оешмасы алмашынуга, ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүгә, мөрәҗәгать итүченең үлеменә) барлыкка килү турында вәкаләтле органга мондый хәлләр килеп чыкканнан соң бер айдан да соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

3.6. Түләү тукталуга китергән шартлар барлыкка килгәндә, түләү әлеге шартлар туган айдан соң килгән айдан туктатыла.

3.7. Белә торып дөрес булмаган белешмәләр булган документлар тапшыру, өстәмә компенсация алу хокукына йогынты ясый торган белешмәләрне яшерү нәтиҗәсендә артык түләнгән компенсаци суммалары мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләтле органның казначылык счетына кертү юлы белән, ә мөрәҗәгать итүче баш тарткан очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә түләтелә.

3.8. Вәкаләтле орган гаебе белән вакытында алынмаган компенсация узган вакыт өчен срокны чикләмичә түләнә.

3.9. Мөрәҗәгать итүче вафат булган очракта, исәпләнгән, әмма яшәгәндә түләнмәгән компенсация суммалары мирас составына кертелә һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гомуми нигезләрдә мирас итеп тапшырыла.

3.10. Компенсация бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.